**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлегенең Коноваловка торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**18.11.2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Коноваловка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Коноваловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Коноваловка торак пункты территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
2) Коноваловка торак пункты, Тынычлык урамы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ташу, вак таш салу);

3.Әлеге карарны Коноваловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге башлыгы_______________ М.Н. Галимҗанов